КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 август г.Казань № 673

2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу механизм карарга теркәлгән 2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 19 август, 673 нче
карары белән расланды

2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы (алга таба – муниципаль район) бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Башка бюджетара трансфертлар 2024 елда әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

4. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка бюджетара трансфертлар бирүгә бүлеп бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты акты белән билгеләнә.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

муниципаль районның 2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкару, проектлау, демонтаж үткәрү чараларын гамәлгә ашыру өлешендә чыгым йөкләмәләре билгеләнә торган хокукый акты булу;

муниципаль район бюджетында (муниципаль район бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре булу;

әлеге Тәртипнең 10 пункты нигезендә Министрлык һәм муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзү.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка (алга таба – заявка);

заявкага кул куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документ;

муниципаль районның әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән хокукый акты күчермәсе;

муниципаль районның 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына муниципаль район бюджеты (муниципаль район бюджетының җыелма бюджет исемлеге) турындагы карарыннан муниципаль район бюджетында муниципаль районның финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуын раслый торган өземтә;

«Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләре» объекты буенча билгеләнгән тәртиптә расланган проект-смета документациясе.

7. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә карап тикшерә;

заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә башка бюджетара трансферт бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

башка бюджетара трансферт бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә башка бюджетара трансферт бирү яисә бирүдән баш тарту турында кабул ителгән карар хакында муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органына язма хәбәр бирә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль район тарафыннан әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансферт бирү шартлары үтәлмәү;

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

9. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлык белән муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы арасында төзелә торган Килешү нигезендә бирелә.

10. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе һәм сроклары;

финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисап, башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап бирү формалары һәм сроклары;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль район тарафыннан Килешүдә каралган башка бюджетара трансфертлардан файдалану шартлары үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен якларның җаваплылыгы.

11. Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе – әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән, башкарылган проект, төзелеш-торгызу эшләре, шул исәптән демонтаж эшләре.

Башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсенә ирешү срогы – 2024 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

12. Финанс белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар юнәлеше булып түбәндәге эшләр тора:

«Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләре» объекты буенча проект-смета документациясен эшләү;

Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләре, шул исәптән демонтаж эшләре.

13. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәсенең Килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән күрсәткечләрен чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык тарафыннан Килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә муниципаль районның финанс органына ачылган муниципаль район бюджетының бердәм счетына күчерелә.

15. Муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турында хисап һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап тапшыра.

16. Муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

17. Әлеге Тәртип нигезендә алынган, 2025 елның 1 гыйнварына карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар 2025 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керменә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия

Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә түләтелергә тиеш.

18. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

муниципаль район тарафыннан Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылу;

муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән срокта финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгымнар турындагы хисапны һәм башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турындагы хисапны тапшырмау;

муниципаль район тарафыннан Килешүдә билгеләнгән срокларда башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешмәү.

19. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланылмаган һәм (яки) муниципаль район тарафыннан аларны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль район тарафыннан әлеге Тәртипнең 17, 18 пунктлары нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

20. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Тәртип һәм Килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

21. Муниципаль район тарафынанн башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры
_________________________________ ка
___________________________________
(муниципаль район җитәкчесе (аның вазыйфаларын
____________________________________ нан
башкаручы зат) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) (тулысынча))

2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирүгә заявка

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел,

19 август, 673 нче карары белән расланган 2024 елның 6 апрелендә Нурлат шәһәре, Завод урамы, 9 нчы йорт адресы буенча газ-һава катнашмасы шартлау аркасында зыян күргән торак йортта төзелеш һәм торгызу эшләрен башкаруга, проектлауга, демонтаж үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен 2024 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе нигезендә

_______________________________________________________________________________

(муниципаль район исеме)

_______________________________________________________________________________

(чара исеме, башка бюджетара трансферт бирү максаты)

_______________________________________________________________________________,

________________(__________________________________) сум ____ тиен күләмендә

(сумма цифрлар белән) (сумманы тутырып язу)

башка бюджетара трансферт бирүегезне сорыйм.

Әлеге заявкада бирелгән белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

Дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар биргән өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләр буенча башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылган очракта, бирелгән башка бюджетара трансфертны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарырга тиеш булуым турында хәбәрдармын.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан ______________

_______________________________________________________________________________

(муниципаль район исеме)

карата башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризамын.

Җитәкче

(аның вазыйфаларын башкаручы зат) _______________ / _____________________________________/

(имза) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.

Дата: 2024 ел, «__» ________

________________________________